**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БАШЛЫГЫ**

423740, Актаныш авылы, Ленин пр.,
17нче йорт. Тел. 3-44-44

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ГЛАВА АКТАНЫШСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423740, село Актаныш, пр. Ленина,
дом 17. Тел. 3-44-44

КАРАР ПОСТАНОВЛЕНИЕ

_______ №_________

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башлыгының 2018 елның 17 сентябрендәге ПР-228 карары белән расланган 2019-2022 елга Актаныш муниципаль районында хокук бозуларны профилактикалау буенча муниципаль комплекслы программага үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә хокук бозуларны профилактикалау системасы нигезләре турында» 2016 елның 23 июнендәге 182-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә һәм 2019-2022 елларга Актаныш муниципаль районында хокук бозуларны профилактикалау буенча муниципаль комплекслы программаны финанслау чыгымнарын ачыклау максатларында,
**КАРАР БИРӘМ:**

1. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башлыгының «2019-2022 елларга Актаныш муниципаль районында хокук бозуларны профилактикалау буенча комплекслы программа» раслау турында» 2018 елның 17 сентябрендәге ПР-228 номерлы карары белән расланган 2019-2022 елларга Актаныш муниципаль районында хокук бозуларны профилактикалау буенча муниципаль комплекслы программага «Программа бүлекләре буенча финанс чараларын исәпләү» таблицасын бәян итеп, әлеге карарга кушымта нигезендә (1 нче кушымта) үзгәреш кертергә.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый порталында һәм Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында бастырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары Л.Ф.Нурлыевага йөкләргә.

Муниципаль район Башлыгы Э.Н.Фәттахов

Татарстан Республикасы
Актаныш муниципаль районы
Башлыгы карарына
____________ ел, №-___
1 нче кушымта

**Программаның бүлекләре буенча финанс чараларын исәпләү**

| Бүлек № | Бүлекнең исеме | Бер елга акча суммасы (мең сумнарда) | | | | Барлык акчалар |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 2019 | 2020 | 2021 | 2022 | 2019-2022г |
| 1. | Хокук бозуларны профилактикалауны норматив-хокукый тәэмин итү | 9,0 | 0 | 0 | 9,0 | 18,0 |
| 2. | Хокук бозуларны профилактикалау | 7401,5 | 7357,8 | 6487,4 | 5754,1 | 27000,8 |
| 3. | Хокук бозуларны профилактикалауны мәгълүмати һәм фәнни-методик тәэмин итү | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 |
| | **Нәтиҗә:** | 7410,5 | 7357,8 | 6487,4 | 5763,1 | 27018,8 |